СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
31 июля 2015 года

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
№552

Зеленодольск муниципаль районының аерым муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында инициативаны тәкъдим итү хакында

2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 12 статьясы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. «Зеленодольск шәһәре», «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре, Зеленодольск муниципаль районының Әйшә һәм Октябрь авыл җирлекләре чикләрен үзгәртү турында, алар составына керүче торак пунктларны башка җирлекләр территорияләренә кертмәү һәм әлеге карарга кушымта нигезендә аларның чикләрен билгеләү инициативасы белән чыгарга.
2. Зеленодольск муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарына, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән, тиешле муниципаль берәмлекләрнең чикләрен закон белән билгеләнгән тәртиптә үзгәртү турында халык фикерен ачыклауны тәэмин итәргә.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына, «Зеленодольск муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше сәясәте идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән чараларны әзерләүдә һәм үткәрүдә Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнарына ярдәм итәргә.
4. Әлеге карарны 2015 елның 1 августына кадәр Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советы законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.
6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**